**Салахова Р.Р.**

# География һәм экология институтында укучы студентларга татар телен укыту үзенчәлекләре

Терминология – шактый катлаулы өлкә. Кайсы гына телне алма, әлеге телдә төрле тармакларга караган терминнар ясалып тора, искергәннәре югала, кулланылыштан төшеп кала. Теге яисә бу телдәге терминнар системасының эшләнү, эшкәртелү дәрәҗәсе гомуми тел үсеше турында фикер булдыра. География белгечлеген үзләштерүче студентларга (татар төркеме) географик терминнарның тарихи үсеше, генетик төркемчәләре һәм структур төзелеше белән бәйле мәгълүмат бирү, фәнни планда гына түгел, гомумән, дөньяны танып белү юнәлешендә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, су чыганаклары атамаларын гына алыйк. Галимнәр фикеренчә, гидронимнар ялгызлык исемнәрнең барысыннан да алдарак барлыкка килгән дип саналалар. Шуңа күрә аларны өйрәнү татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләрен  хәл иткәндә дә гаять әһәмиятле мәгълүматлар бирә. Әйтик, елга сүзе элек уртача зурлыктагы агым суларны атау өчен генә файдаланылган. Хәзерге татар телендә исә ул сүз зур һәм кечкенә елгаларга карата да кулланыла: Идел елгасы, Чулман елгасы, Зәй елгасы һ.б. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә  елга – “башланган  урыннан койган җиренә кадәр үзе салган үзәнлек буенча табигый рәвештә туктаусыз агып торган су” дигәнне аңлата. Инеш - әдәби телдә кечкенә елганы белдерә. Бай  атамасы “елга, коры елга” төшенчәләрендә йөри. Урта Азиядә ул шулай ук коры үзәнне белдерү өчен дә кулланыла. Сарыкамыш иңкүлегеннән Каспий диңгезенә кадәр сузылган борынгы үзән хәзерге көнгә кадәр Узбой (okuz +boi – “елга яны”) дип атала Тармак -  термины “елга кушылдыгы”н аңлата. Тармак татарлар яши торган урыннарда гидронимнар һәм микротопонимнар буларак кулланыла. Чишмә - “җир астыннан агып, бәреп чыга торган су чыганагы”. Чишмә сүзе фарсы телендәге “күз” мәгънәсенә ия булган чашм – чешм яисә “чыганак, чишмә”не белдерә торган чашме сүзенә барып тоташа.  Үзән – хәзерге әдәби телдә “су юлы, су аккан эз” мәгънәләрен белдерә. Үзән сүзе элек елга төшенчәсендә кулланылган. Хәзер ул елга атамаларында очрый [1, 37-38].

Географик терминнарның сүзлек составы төрле һәм аларда берничә генетик катлам күзәтелә. Әлбәттә, иң беренче чиратта, бу төрки чыгышлы сүзләр: *агым, авышлык, утырма, сазлык, тау, урман* һ.б.  Иҗтимагый тормыштагы күптөрле вакыйгалар, илләр арасындагы бәйләнешләрнең үсүе географик терминнарның да кабул ителүенә китергән.  *Һава, диңгез, дөнья, табигать, матдә* кебек гарәп-фарсы алынмалары бүгенге көндә алынма буларак кабул да ителми. Алар тезмә терминнар составында да бик күп: *табигый шартлар, һава хәрәкәте, диңгез агымы* һ.б.

Бүгенге көндә иң актив кулланылган географик терминар арасында рус һәм аның аша европа телләреннән кергән алынмалар да зур күпчелекне алып тора.  Мәсәлән, француз теленнән кергән алынма терминнар: *район, анклав, популяция, депопуляция* һ.б., инглиз теленнән: *импорт, экспорт* һ.б.,  латин теленнән: *ассимиляция, регион, рекреация, урбанизация* һ.б.[4:84]. Күпчелек географик атамалар фонетик яктан үзгәрешләргә дучар ителмәгән(*океан, пассат, биосфера, материк, компас, муссон, климат*), әмма шул ук вакытта бу сүзләрнең татар теленең грамматик системасы өчен хас категорияләрне алуы, сүзьясалыш процессында актив катнашулары билгеле: *биеклек пояслыгы, ритмлылык, литосфера плитасы, мәрҗән рифлары* һ.б.

Белгечлек белән бәйле  ясалма терминнарның ясалыш һәм төзелеш үзенчәлекләрен өйрәтү дә студентка үз белгечлеге белән бәйле белем туплау өчен кирәкле материал булып тора. Беренче чиратта төзелеше буенча аларның гади(синтетик) һәм катлаулы(аналитик) төрләргә бүленүен һәм мондый бүленешнең сүз ясалыш ысулларына бәйле булуын аңлату зарур. Студентлар бер үк вакытта татар теленең сүз ясалыш ысуллары һәм географик атамаларның ясалышы белән танышалар.  Мәсәлән, кушымчалау ысулы белән ясалган географик атамалар, тамыр һәм алынма сүзләр кебек үк, синтетик төзелешле сүзләр рәтенә керәләр: *киң+-**лек**, тау+-**лык**, калку+-**лык**, яссы+-**лык**, борыл+-**ма**, утыр+-**ма**, чере+-**мә**, таш+-**кын**, уп+-**кын**, шарла+-**(в)ык*** кебек сүзләр моның ачык мисалы булып торалар. Әмма татар телендәге геграфик атамаларның зур күпчелеген кушма (аналитак) төзелешле терминнар тәшкил итә. Билгеле булганча, кушма сүзләр ясалышында ким дигәндә ике мөстәкыйль мәгънәле сүз катнаша, һәм алар үзара берегеп бер төшенчә, бер лексик мәгънә белдерә башлыйлар[5: 46]. Ике яки берничә нигез кушылуыннан түбәндәге географик атамалар барлыкка килгән: *ярымшар, Бөтендөнья океаны, комташлар*. Сүзтезмәнең лексикалашуыннан барлыкка килгән кушма географик атамалар: *көньяк, төньяк, көнбатыш* һ.б. Соңгы төркемне сүзтезмәнең кушымча алып, кушма сүзгә күчүе нигзендә барлыкка килгән географик атамалар тәшкил итә: *сусаклаг**ыч**, дымүлчәг**еч*** һ.б.

Телгә өйрәтү дәресләрендә тәрҗемә методын куллану география белгечлеген үзләштерүче студентларга үз белгечлеге белән бәйле булган теләсә нинди материал белән эшли алуга, ягъни  текстны татарчадан русчага һәм, киресенчә, русчадан татарчага дөрес тәрҗемә итә белүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Билгеле булганча, тәрҗемә методы чит телне туган тел аша өйрәнү белән бәйле. Бу вакытта барлык яңа сүзләр һәм әйтелмәләр укучыларның туган теленә тәрҗемә ителә, ягъни әлеге очракта төп игътибар тәрҗемәгә бирелә. Булачак географларга “История карт”, “Озера и водохранилища”, “Вулканы” , “Грозы”, “Осадки” кебек эчтәлектәге текстлар югарыда санап кителгән факторлар белән бергә, булачак белгечкә үз белгечлеге турында өстәмә яңа мәгълүмат тупларга да ярдәм итә.

География һәм экология институтында укучы студентларга татар теле дәресләрендә географик терминнарның татарча-русча яки русча-татарча атамаларын өйрәтүгә дә зур игътибар бирелергә тиеш. Бигрәк тә апелятив

лексикага игътибар итү мөһим. Мәсәлән, Мәрҗән диңгезенең тәрҗемәсе - Коралловое море, Әдрән диңгез - Адриатическое море, Гарәп диңгезе - Аравийское море, Көнчыгыш Себер диңгезе - Восточно-Сибирское море, Сары диңгез - Желтое море, Кариб диңгезе - Карибское море һ.б. Топонимика һәм гидрония белән бәйле ялгызлык исемнәрнең тәрҗемә вариантларын үзләштерү өчен, студентлар белән татар телендә төрле викториналар, конкурслар уздыру тиешле нәтиҗәләргә ирешүдә уңышлы алымнардан санала.

Телгә өйрәтү дәресләрендә укучыларда аралашу ихтыяҗы булдырыла, аның ярдәмендә һөнәри һәм гомуммәдәни әһәмиятле мәгълүмат алу теләген уяту бурычы куела. Аралашу өчен сайлап алынган теманың студент сайлаган һөнәр белән бәйле булуы әһәмиятле, чөнки студент югары һөнәри белем бирү уку йортына билгеле бер һөнәр үзләштерү өчен укырга керә һәм булачак һөнәре белән бәйле теләсә нинди мәгълүмат анда кызыксыну уятырга сәләтле. Җир, ут, су һ.б табигать күренешләре турындагы табышмаклар, җырлар, мәкаль-әйтемнәр, легенда-риваятьләр дә география белгечлеген үзләштерүче студентның татар теле дәресләренең эчтәлеген баета торган кыйммәтле тел материалы булып торалар.

Шулай итеп, татар теле дәресләрендә кулланылган тел материалының студент үзләштерелә торган белгечлек белән бәйле булуы студентка үз һөнәрен нигезле үзләштерергә һәм икетеллелек шартларында үзе сайлаган өлкәдә төпле, иҗади эшләргә мөмкинлек бирә.

## Әдәбият


1. Гарипова Ф.Г.Исемнәрдә ил тарихы /Ф.Г.Гарипова. – Казан:Татарстан китап нәшрияты, 1994. – 260 б.
2. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзьясалышы/Ф.Ә.Ганиев. – Казан: Мәгариф, 2000, -288 б.
3. Сафиуллина Ф.С.Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология /Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999.
4. Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология нигезләре/ Ф.С.Фасеев. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1969. – 200б.
5. Хисамова Ф.М. Татар тле морфологиясе. / Ф.М.Хисамова. – Казан: Мәгариф, 2006.